РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 17 декабре Кукмара ш. № 99

Кукмара муниципаль районы Советының кайбер карарларының үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 16.1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы карар бирде:

1. Әлеге карар үз көченә кергән көннән түбәндәгеләрен үз көчен югалткан дип таныргa:

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән аерым башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Кукмара муниципаль район Советының 2017 елның 18 августындагы 113 номерлы карары;

“Кукмара муниципаль район Советының 2017 елның 18 августындагы 113 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән аерым башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» Кукмара муниципаль район Советының 2018 елның 16 ноябрендәге 185 номерлы карары

«Кукмара муниципаль район Советының 2017 елның 18 августындагы 113 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән аерым башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән

идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» Кукмара муниципаль район Советының 2019 елның 22 мартындагы 209 номерлы карары

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев